Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11.11.2021 Менделеевск шәһәре № 754

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2021 нче елның
7 нче апрелендәге 244 нче номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе административ хокук бозулар кодексының 32.13 статьясы нигезендә, мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәзаларны үтәү өчен шартлар тудыру максатыннан, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 нче елның 7 нче апрелендәге 244 нче номерлы “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә мәҗбүри эш төрләрен һәм административ җәзаларны үтәтү оешмаларының исемлеген билгеләү турында”гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәзаларны үтәтү оешмалары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә: «5. Татарстан Республикасы Менделеевск суд районы буенча 1 нче суд участогы.»;

1.2. түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә: «6. Татарстан Республикасы Менделеевск суд районы буенча 2 нче суд участогы.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru “Норматив документлар” бүлегендә урнаштырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http//pravo.tatarstan.ru бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы А.Н. Сафаргалинга йөкләргә.

Җитәкче Р. И. Беляев

Килешенгән:
Юридик бүлек башлыгы Е. С. Царева